Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLIV-7**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 22 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында “Халык контроле” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына килеп ирешә торган хәбәрнамәләрне карау буенча эш нәтиҗәләре турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Р. Җамалиевның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында “Халык контроле” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына килеп ирешә торган хәбәрнамәләрне карау буенча эш нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында “Халык контроле” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына килеп ирешә торган хәбәрнамәләрне карау буенча эш нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Җаваплы затларга (урындагы кешеләргә) тәкъдим итәргә:

“Халык контроле” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган хәбәрнамәләрне карау буенча эшне дәвам итәргә;

бүгенге көндә “планлаштырылган” стадиясендә торган гаризалар буенча билгеләнгән срокта конкрет карарлар кабул итәргә;

гаммәви мәгълүмат чараларында “Халык контроле” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшен актив рәвештә яктыртырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов